Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Яңа Никольский авыл җирлегенең
Сосновка торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы
КАРАРЫ

6 декабрь 2021 ел №5

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2021 елның 4 декабрендә 13 сәгать 30 минутта узган гражданнарның җыен нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге: «Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Яңа Никольский авыл җирлегенең Сосновка бистәсе территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән 6000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрүгә юнәлдерергә килешәсезме: су белән тәэмин итү системасын (скважиналар бораулау), юлларны норматив хәлгә китерү, кышкы һәм җәйге чорда юлларны карап тоту, сметалар төзү өчен түләү, техник күзәтү үткәрү һәм авыл җирлеге милкенә рәсмиләштерү?» сораулары буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 142 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 73 кеше, бу 51,4% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 73 «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; гражданнар җыенында катнашучыларның 0 «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Никольский авыл җирлегенең Сосновка торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2.Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Никольский авыл җирлегенең Сосновка бистәсе яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән үзара салым средстволарын 2022 елда 6000 сум күләмендә кертергә.

3. Җыелган үзара салым средстволарын җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә: су белән тәэмин итү системасын (скважиналар бораулау), юлларны норматив хәлгә китерү, кышкы һәм җәйге чорда юлларны карап тоту, сметалар төзү өчен түләү, техник күзәтү үткәрү һәм авыл җирлеге милкенә рәсмиләштерү.

4. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырырга, Сосновка бистәсе, Лесная урамы, 31 йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче Г.А.Кәримова